## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**19.01.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә 2021 елның 19 гыйнварында 14 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге мәсьәләләр буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

1. Кошман авыл җирлеге башлыгының 2020 елгы эш йомгаклары буенча хисабы һәм 2021 елга план.
2. Каты коммуналь калдыкларны капчык белән җыю.
3. Кошман авыл җирлегендә яшәүчеләрнең әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәмәгән туганнарын күмүне түләүле шартларда башкару (5 мең сум).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Авыл җирлеге гражданнар җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 124 кеше (әлеге җыенда гына катнашучы) кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 124 кеше, бу 100 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 124 гражданнар җыенында катнашучы, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Санап үтелгәннәргә нигезләнеп, гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Кошман авыл җирлеге башлыгының 2020 елгы эш йомгаклары буенча хисабын һәм 2021 елга планын игътибарга алырга.
2. Каты коммуналь калдыкларны капчык белән җыярга.
3. Кошман авыл җирлегендә яшәүчеләрнең әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәмәгән туганнарын күмүне түләүле шартларда башкарырга (5 мең сум).
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, рәсми сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Кайбыч муниципаль районы
Кошман авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Сафина